# КАРАР

## Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына Трудовой торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 22 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 22 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Трудовой торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар 2025 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү, 2 нче төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр өчен түләүләр күләме гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итүе һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү белән килешәсезме:

- Тынычлык, Домостроителей, Пролетарская урамнарында юлларны төзекләндерүгә (материалларны сатып алу һәм китеру (вак таш, гравий, асфальтобетон, яисә асфальтобетон катнашмасы) тигезләү һәм тыгызлау эшләрен башкару, килешү буенча эшләр өчен түләү)

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 378 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 209 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 186 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 23 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Трудовой торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.
2. «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Трудовой торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, 2025 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү, 2 нче төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр өчен түләүләр күләме гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итүе һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү белән килешәсезме:

-Тынычлык, Домостроителей, Пролетарская урамнарында юлларны төзекләндерүгә (материалларны сатып алу һәм китеру (вак таш, гравий, асфальтобетон, яисә асфальтобетон катнашмасы) тигезләү һәм тыгызлау эшләрен башкару, килешү буенча эшләр өчен түләү)

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Майская Горка авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Майская Горка авыл җирлеге башлыгы А.П. Морозов